**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Бикүле авыл җирлегенең Бикүле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

«20» октябрь  2023 ел                                                                                  № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге Бикүле авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Бикүле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 3000,00 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Авыл эчендәге юлларны ремонтлау (туфрак таштан түшәм күтәрү, вак ташны күмү);
- Су белән тәэмин итү чыганакларын норматив хәлгә китерү;

Парк зонасын һәм стадионны төзекләндерү;

- Буаны ремонтлау (дамба);
- Янгын сүндерү боксын җылыту буенча чаралар үткәрү;
- Бикүле торак пунктында зиратларны тоту;
- Трактор өчен арба сатып алу.

Гражданнар җыенында рәислек итүче:                                    А.М.Шакирова

Бикүле авыл җирлеге башлыгы                                                  А.М.Шакирова